РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«16» июль 2020 ел г. Альметьевск № 954

**Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районы территориясендә урнашкан дәүләт медицина оешмаларында эшләү өчен медицина югары уку йортларында укучы студентларга, ординатура программасы буенча укучы затларга стимуллаштыручы түләүләр турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 30 декабрендәге 2310 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Төзәтүләр тәртибендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районы территориясендә урнашкан дәүләт медицина оешмаларында эшләү өчен медицина югары уку йортларында укучы студентларга, ординатура программасы буенча укучы затларга стимуллаштыручы түләүләр турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 30 декабрендәге 2310 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарга 1 нче кушымтада:

1 бүлекнең 1.7 пунктында «елга ике тапкыр түләнә» сүзләрен «елга бер тапкыр түләнә» сүзләренә алмаштырырга;

1 бүлекнең 1.10 пунктындагы «г» пунктчасында «елга ике тапкыр, 15 календарь көн дәвамында» сүзләрен «елга бер тапкыр, 20 календарь көн дәвамында» сүзләренә алмаштырырга»;

4 бүлектәге 4.2 пунктының 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-сайлап алу турында мәгълүматны бастырып чыгаруны, дәгъвачыларга таләпләр, сайлап алу сроклары турында - сайлап алу башлану датасына кадәр 10 (ун) эш көненнән дә соңга калмыйча; сайлап алу йомгаклары турында - Әлмәт муниципаль районы сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алу тәмамланганнан соң 10 (ун) эш көненнән дә соңга калмыйча «Альметьевский Вестник» газетасында мәгълүмат бастырып чыгаруны тәэмин итә;»;

4 пунктның 4.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
«-белгечкә характеристика кушымтасы белән эш урыныннан белешмә.».

1.2. нигезләмәнең 1 нче кушымтасында:

комиссия составына кертергә:

Суфиярова М.Г. – комиссия әгъзасы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Әлмәт муниципаль районы буенча Сәламәтлек саклау идарәсе җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча);

Комиссия составыннан В.Р. Головинаны чыгарырга.

1.3. нигезләмәгә 2 нче кушымтаның 3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Сәламәтлек саклау учреждениесенең беренчел звеносына аккредитациядән соң эшкә урнаштырылган яшь белгечкә субсидияләр.

3.1. Сәламәтлек саклау учреждениесенең беренчел звеносында аккредитациядән соң эшкә урнаштырылган яшь белгечнең яше 35 елдан артмаска тиеш.

3.2. Белгеч һәм сәламәтлек саклау учреждениесе арасында 5 елдан да ким булмаган вакытка хезмәт килешүе төзү.

3.3. Белгечнең фәнни, бөтенроссия, ведомство, төбәк басмасында бастырып чыгару сәләте - 1 балл (һәр басмага).

3.4. Югары медицина белеме турында бик яхшы билгесе белән диплом булу - 1 балл.

3.5. Россия Федерациясенең башка төбәгеннән, башка илдән дәгъвачы, җирле прописка юк - 1 балл.

Сәламәтлек саклау учреждениесенең беренчел звеносында аккредитациядән соң эшкә урнаштырылган яшь белгечкә субсидия билгеләгәндә, өстенлек «3.1»-«3.5» пунктчаларында күрсәтелгән критерийлар буенча иң күп балл җыйган дәгъвачыга бирелә.»;

1.4. Нигезләмәгә 2 нче кушымтаның 4 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Ординатурада укыганнан соң сәламәтлек саклау учреждениесенең беренчел звеносына эшкә урнаштырылган яшь белгечкә субсидияләр.

4.1 Ординатурада укыганнан соң, сәламәтлек саклау учреждениесенә эшкә урнаштырылган яшь белгечнең яше 35 елдан артмаска тиеш.

4.2. Белгеч һәм сәламәтлек саклау учреждениесе арасында 5 елдан да ким булмаган вакытка хезмәт килешүе төзү.

4.3. Белгечнең фәнни, бөтенроссия, ведомство, төбәк басмасында бастырып чыгару сәләте - 1 балл (һәр басмага).

4.4. Медицина белгечлеге буенча гомуми эш стажы - 1 балл (ел саен стаж).

4.5. Россия Федерациясенең башка төбәгеннән, башка илдән дәгъвачы, җирле прописка юк - 1 балл.

Ординатурада укыганнан соң сәламәтлек саклау учреждениесенә эшкә урнаштырылган яшь белгечкә субсидия билгеләнгәндә, өстенлек «4.1»-«4.5» пунктчаларында күрсәтелгән критерийлар буенча иң күп балл җыйган дәгъвачыга бирелә.».

2. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Лаптевага йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Н. Гирфанов

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ